**Татарстан Республикасы**

Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге составына керүче
Биек -Тау торак пунктында ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ
турында

2020 елның 30 октябре № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 30 октябрендә узган граждannar җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Биек -Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Биек-Тау торак пунктының Тынычлык урамының юл-урам челтәрен ремонтлау».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 34 граждан кертелгән, 18 кеше тавыш бирүдә катнашкан, бу 52,9% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 18 кеше тавыш бирде;
- «юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Биек-Тау авыл җирлегендә халык җыенын узган дип санарга, халык җыенының нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Биек -Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Биек-Тау торак пунктының Тынычлык урамының юл-урам челтәрен ремонтлау" - соравы буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan электрон адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм www.yutaza.tatar.ru электрон адресы буенча Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.
4. Әлеге карар халыкка рәсми игълан иткән көннән үз көченә керә.

Җыенда рәислек итүче Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы: Р.К.Вәлиев